# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

05 декабрь 2019 ел №1

2019 елның 17 ноябреннән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Ташсу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 17 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Ташсу авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Ташсу авылы эчендәге юлларга вак таш сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 79 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 40 кеше, бу 50,6%ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 39 катнашучы тавыш бирде;

“Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 1кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Ташсу торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Ташсу авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”

а) Ташсу авылы эчендәге юлларга вак таш сатып алу” - дигән мәсьәлә буенча кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Суыксу авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев